**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«11» 12 2024 ел Яр Чаллы ш. №137

Биклән авыл җирлеге генераль планы проекты буенча халык тыңлауларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай муниципаль районы уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Биклән авыл җирлеге генераль планы проекты буенча халык тыңлауларын билгеләргә.
2. Халык тыңлауларын оештыручы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына җирле үзидарә турында, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнар нигезендә халык тыңлауларын оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.
3. Халык тыңлауларын үткәрү 2025 елның 11 гыйнвареннән дә соңга калмыйча тәмамланырга тиеш, дип билгеләргә.
4. Әлеге карарны " Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга «https://pravo.tatarstan.ru / һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: https://tukay.tatarstan.ru/, шулай ук «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы»федераль дәүләт мәгълүмат системасында.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең Беренче урынбасары А.Р. Хәбибуллинга йөкләргә.

Район Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.И. Закиров